РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2024 г. г. Альметьевск № 155

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 150 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Уставының 29 статьясы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 150 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2015 елның 06 маендагы 178 номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге 11 номерлы, 2018 елның 17 июлендәге 124 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 127 номерлы, 2021 елның 28 сентябрендәге 45 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.2 пунктча өстәргә:

«4.2. 2025 елда - 1,2 процент, 2026 елда - 1,2 процент, 2027 елда - 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда - 2 процент гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ - эшлекле үзәкләргә һәм гомуми мәйданы 1000 дән 2000 квадрат метрга кадәр булган сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы биналарга карата:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгәннәр,

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы 10 пунктының икенче абзацында каралган».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов